**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 март № 166

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1103 нче карары белән расланган Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1103 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 сентябрь, 649 нчы, 2015 ел, 12 март, 147 нче; 2015 ел, 10 декабрь, 937 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр шартнамәдә күздә тотылган очракларда хисап елыннан соң килә торган елның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы субсидияне кире кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына әлеге акчаны кире кайтару буенча законнар белән билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.»;

әлеге Тәртипкә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\166.docx

Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 24 март, 166 нчы карары редакциясендә)

2016 елга Идел буе федераль округы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе субъектлары аэропортларына Татарстан Республикасы аэропортларыннан һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары | | Бер атнага рейсларның ешлыгы | Махсус тарифның иң чик күләме, сум | Бер юнәлештә бер рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына бирелә торган субсидия күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| | шәһәр | шәһәр | | | |
| 1 | Казан | Оренбург | 3 | | |
| 2 | Казан | Самара | 6 | | |
| 3 | Казан | Киров | 7 | | |
| 4 | Казан | Пенза | 3 | | |
| 5 | Түбән Кама | Түбән Новгород | 3 | | |
| 6 | Казан | Түбән Новгород | 5 | | |
| 7 | Казан | Пермь | 6 | | |
| 8 | Түбән Кама | Пермь | 3 | | |

_______________________________